Сафина, Ф. Китап - киңәшчең синең, дустың, ярдәмчең синең / Ф. Сафина, Г. Дусаева, Л. Егорова // Ачык дәрес. Мәктәп. – 2025. – №7 (254). – Б. 14-15.



дигән сорауга җавапларны гомумиләштереп, кагыйдәләр чыгару.
Су белән дус бул!
Дәрес туклан! Яшелчә, җиләк-җимешләрне юып аша!
Күбрәк хәрәкәтлән! Спортны ярат!
Иртән физарядка ясарга онытма!
Чынык!
Күңелең саф, чиста булсын!
Укытучы. Җәен футбол яратсагыз,
Кышын хоккей уйнагыз.
Хәрәкәтле уеннардан
Беркайчан да туймагыз.
Чаңгыда да шуыгыз сез,
Чабыгыз, узышыгыз.
Таза булгач, якты булыр
Киләчәк тормышыгыз.
Җыр: " Өйрәтәләр мәктәпләрдә"
Иртән ничек ашарга
Кичен ничек йокларга
Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә
Исәнлекнең, саулыкның,
Кадерләрен белергә,
Өйрәтәләр мәктәпләрдә,мәктәпләрдә.
Яшелчәләр ашарга,
Витаминнар җыярга
Өйрәтәләр мәктәпләрдә,мәктәпләрдә
Спортны дус итәргә
Ялкаулыкны җиңәргә,
Өйрәтәләр мәктәпләрдә,мәктәпләрдә.
Дус һәм тату яшәргә,
Һәм сәламәт булырга
Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә.
Чисталыкны сакларга
Гимнастика ясарга
Өйрәтәләр мәктәпләрдә, мәктәпләрдә.

# Китап - киңәшчең синең, дустың, ярдәмчең синең...

**Сафина Фирдәвес**
**Дусаева Гөлнара**
**Егорова Лариса**
Яр Чаллы шәһәре "Шәһәр үзәк китапханәсе"

**Максат:** Китап укуның әһәмиятен аңлату. Балаларда китапка мәхәббәт тәрбияләү, китап укуның белем алу, фикерләү сәләтен үстерүдәге ролен күрсәтү.

Укучыларда китапка карата кызыксыну уяту; китап укырга теләк тудыру.

Китапны – якын дус, киңәшче итеп кабул итәргә өйрәтү.

Укучыларда китапка карата сакчыл һәм ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү, аның - белем, мәдәният чыганагы буларак кадерен аңларга өйрәтү.

Бик күп телләрне белсә дә,
Сөйләшми бер телдә дә.
Өйрәним, дисәң, өйрәтә,
Карышмый беркемгә дә.
Ул нәрсә? ( Китап.)

Китапханәче: Безнең бүгенге кичәбез дә китап турында. Ул "Китап - киңәшчең синең, дустың, ярдәмчең синең...» дип атала. (Китаплар күргәзмәсе белән таныштыру).

Китап — иң акыллы киңәшчеләрнең берсе. Китап һәр кешегә хезмәттә булыша, ул кешеләрне бәладән коткара, тормышны танып белергә өйрәтә. Китап кешегә үсәргә һәм халыкның аңын баетырга мөмкинлек бирә. «Китап кешене галәмнең хуҗасы итә», - дип язган П. А. Павленко.

Бала чакта китап укудан да күңелле нәрсә юктыр. Бигрәк тә ул китапта сиңа таныш хәлләр турында язылган булса, аны кат-кат укыйсы, алар турында иптәшләреңә сөйлисе, шигырьләрен күңелдән ятлыйсы килә. Андый китаплар - безне бала чактан зур тормышка озатып калучы, гомер буе хәтердә яңарып торучы иң якын дусларыбыз. Китап - канатлы ул! Китап, үзенең канатына утыртып, сине мең елга артка илтеп ташлый, яисә ул кешене йөз елга алга алып китә.

Китап - әнә шундый могҗизалы нәрсә ул. «Яхшы китаплар уку - үткән заманның яхшы кешеләре белән сөйләшү ул», - дип язган Р. Декарт.

Россиядә китап басу эшен 1564 нче елда Иван Федоров белән Петр Мстиславец башлап җибәргән.

Дөньяда иң кыйммәтле һәм иң авыр китап - «Изге Иоанн хакыйкате». Ул Швейцария акчасы белән ике мең франк бәяләнә. Кыйммәтле ташлар белән бизәлгән бронза тышлыгы гына да 120 килограмм. Йөз илле битле бу китап 300 сарык тиресеннән ясалган иң яхшы пергаменттан эшләнгән. Китапның форматы - 75х64.

Дөньяда иң зур китапханә - Россия дәүләт китапханәсе. Аның киштәләрендә егерме ике миллион китап бар. Аларны тезеп кую өчен дә ун километр озынлыктагы киштә кирәк булыр иде.

Дөньядагы иң кечкенә китапханә Һиндстанның Амритсар шәһәрендә. Кыйммәтле мәрмәрдән салынган, бакыр һәм алтын белән бизәлгән бу китапханәдә бары тик бер генә китап саклана.

Китап - дөньяны таныш белергә ярдәм итә торган ачкыч ул. Аңарда кешелек акылының океаны бар. Китап уку - иң яхшы белем алу. Һәр кешенең үзенә ошаган бер китабы була. Бу кеше, китапта язылганнарны һәрвакыт искә төшереп, авырлыкларны җиңә.

«Китап - бакча, андагы язулар - шул бакчаның гөлләре», - дип әйткән Каюм Насыйри. Кем укымый, шул бернәрсә турында да уйламый. Белем алуның иң яхшы юлы - уку. Тиеннәрдән сумнар җыелгандай, укылган бөртекләрдән белем туплана.

Китап - белем чишмәсе. Китап - безнең заманның тормышы. Китап - бер буынның икенче буынга рухи васыяте, гомернең соңгы чигенә житкән аксакалның яңа гына яши башлаган кешегә киңәше. Китап битләре, керфекләр кебек, күзне ачалар.

Кулга нинди генә китап алсак та, ул безне игелеккә, шәфкатьле булырга, матурлыкны күрә белергә өйрәтә. Халыкта китап турында бик күп мәкальләр бар.

Китап- тормыш көзгесе.
Китап- галим, телсез мөгаллим.
Китапсыз өй - кояшсыз көн.
Алтын жирдән табыла, белем китаптан.

Китап дусты кешеләрнең
Һәм иң якын сердәше.
Һәрвакытта кирәк була
Безгә китап киңәше.

Кечкенә дустым!

- Караңгы урында укыма, күзләреңне бозарсың.
- Укыганда, яктылык күзләреңә түгел, китапка төшсен;
- Минем битләремне ачканда бармагыңны төкерекләмә, битләремне өстән, почмактан ача башла;
- Тукталып калган урында карандаш яки тырнак белән эз ясама, кыстыргыч куй;
- Мине кояшка куйма, югыйсә тышым кибеп кубар, битләрем саргаер;
- Рәсемнәремне буяма. Ертылган битләремне ябыштыр;
- Мине өстәлгә куйганчы, өстәл өстен кара: юеш түгелме, икмәк валчыклары юкмы?
- Әгәр миндәге әсәрләрне яратып укыгансың икән, башка иптәшләреңә дә тәкъдим ит.

Кулыңа китап алдың,
Шундый матур рәсемле.
Рәссамнар бик тырышып
Ясаган ул рәсемне.
Ә кәгазен ясарга
Күпләрнең көче кергән.
Кәгазьне яшел дустыбыз
Агач-куаклар биргән .
Беркайчан да китапның
Үткән юлын онытма.
Рәнжетмә син китапны,
Аның битләрен ертма.
Әбиләр дә авырый,
Бәбиләр дә авырый...
Салкын тисә аз гына,
Дару кирәк барсына.
Чирли хәтта китап та.
Ник көләсең, чынлап та:
Бите төшә, ертыла-
Ул бит көндә тотыла.
Тотам шуңа сак кына,
Авырдымы чак кына,
Чирен шундук күрәм мин,
Дәвасын да беләм мин...
Китапларың чирләсә,
Үз кулыңнан килмәсә,
Миңа китер туп-туры-
Мин бит - китап докторы.

Без китаплар аша тормышны өйрәнәбез, белем алабыз. Чөнки аларда бик күп акыл хәзинәсе тупланган. Ул хәзинәне бернинди компьютер да, телевизор да алыштыра алмый. Китап укып, без белем алабыз, уйланабыз, тормыш итәргә өйрәнәбез. Китап геройларыннан үрнәк алабыз яки кайберләренә охшамаска тырышабыз.

Китап - киңәшчең синең,
Дустың, ярдәмчең синең.
Ул хөрмәткә бик хаклы,
Кадерлә син китапны.
Укы, дустым, син аны.
Китапның син дусты бул.
Бик күп сорауларыңа
Җавап биреп торыр ул.

Китапханәче: Китап – безнең якын дустыбыз. Әгәр үзегезгә дуслар табасыгыз килсә, күбрәк китапханәгә йөрегез, сезнең өчен ишекләребез ачык, хөрмәтле китап сөючеләр!

Әйдәгез барыбыз да китап белән дус булыйк!